РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕТНЕВО-ТУЛУШСКОГО
сельского поселения
Рыбно-Слободского
муниципального района
422644, с.Шетнево-Тулуши
ул.М.Джалиля, д.18,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Балык Бистәсе
муниципаль районы
ЮГАРЫ ЫРГА авыл җирлегенең
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422644, Шетнево-Тулуш,
М.Җәлил урамы, 18.

Тел.: (884 361) 27-451, факс: (884 361) 27-451. электронный адресl: Stul.Rs@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.09.2019 Шумбут авылы №18

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 3 номерлы карары белән расланган күчемсез мөлкәт объектына адрес бирү (үзгәртү, аныклау, юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллекк китерү максатларында, 2019 елның 26 июлендәге “Федераль мәгълүмати адресл система хакында һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомум принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында”гы Федерал законга үзгәрешләр кертү турында” 227-ФЗ номерлы Федераль законга һә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авы җирлеге Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ыр авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Муниципа хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 2 номер карары белән расланган күчемсез мөлкәт объектына адрес бирү (үзгәртү, аныкла юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга ав җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 14 июнендәге 11 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 кушымтаның 1.5 пунктында:

а) “адресация объекты – бер яки берничә күчемсез мөлкәт объекты, ш исәптән җир кишәрлекләре яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафынн билгеләнгән адресларны бирү, үзгәртү, юкка чыгару кагыйдәләре белән каралг очракта, адрес бирелә торган башка объект;” җөмләсен “адресация объекты капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмә

тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башк объект;" җөмләсе белән алмаштырырга;

б) "”'планлаштыру структурасы элементы" – зона (массив), район (шул исәпта торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), бакчачылык, яшелчәчелек һә дача коммерциягә карамаган берләшмәләрен урнаштыру территорияләре;" җөмләсен "планлаштыру структурасы элементы – җирлек, шәһәр округы яисә муниципал районның авылара территориясенең бер өлеше ( квартал, микрорайон, район һә башка шундый элементлар). Планлаштыру структурасы элементларының төрләр Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимия органы тарафыннан билгеләнә." җөмләсе белән алмаштырырга;

в) "адрес - Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплар нигезендә структурлаштырылган һәм шул исәптән планлаштыру структурас элементының (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементының исемен, шулай у адреслау объектын идентификацияләү (тәңгәлләштерү) мөмкинлеген бирә торга цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы тамгаланышын үз эченә алган адресаци объектының урнашу урынының тасвирламасы" җөмләсен "адрес – Росси Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезенд структуралаштырылган һәм шул исәптән урам-юл челтәре элементының исемен һә (яисә) планлаштыру структурасы элементының исемен (кирәк булганда), шулай у адресация объектын идентификацияләү (тәңгәлләштерү) мөмкинлеген бирә торга цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы тамгаланышын үз эченә алган адрес объектыны урнашкан урынын тасвирлау" җөмләсе белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт; адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарста Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnay sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникаци челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарста Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Бaһаутдинов

СОВЕТ ШЕТНЕВО-ТУЛУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634001687 ЮГАРЫ ЫРГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ